ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№546 от «15» 05 2017 г.

2017 елда Мамадыш муниципаль
районы территориясендә гомуми
белем бирү программаларын
үзләштергән укучыларга дәүләт
йомгак аттестациясе үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 1 мартындагы №355-р күрсәтмәсе нигезендә, төп гомуми белем бирү программаларын үзләштергән укучыларга дәүләт йомгак аттестациясен уздыру максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 59 статьясындагы 12, 13 өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Муниципаль район башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ (Габдрахманов И. Н.):

- 2017 елда дәүләт йомгаклау аттестациясе үткәрүне тәэмин итәргә;
- 2017 елда туган телне һәм туган әдәбиятны (туган телдә милли әдәбият) өйрәнгән һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен (алга таба – республика имтиханы) узу өчен Туган тел һәм (яки)туган әдәбият буенча имтиханны сайлаган төп гомуми белем бирү программалары буенча укучылар өчен республика имтиханын үткәрергә;
- үз компетенциясе чикләрендә Дәүләт йомгаклау аттестациясен уздыруны мәгълүмати һәм норматив-хокукый тәэмин итүне гамәлгә ашырырга;
- дәүләт йомгаклау аттестациясен инструктив-методик, оештыру-технологик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

2. Дәүләт йомгаклау аттестациясе чорында муниципаль районда имтихан үткәрү пункты итеп Мамадыш шәһәренең 3 нче урта мәктәбен, Мамадыш шәһәренең ак. К.А.Вәлиев исемендәге 2 нче санлы лицейны билгеләргә.

3. Финанс-бюджет палатасы (А.М. Сергеев) «Мәгариф бүлеге»МКУ чыгымнар сметасы нигезендә дәүләт йомгаклау аттестациясен оештыруга һәм үткәрүне финанслауны күздә тотарга.

4. Россия Эчке эшләр министрлыгының Мамадыш районы буенча бүлегенә бердәм дәүләт имтиханын һәм бердәм республика имтиханын уздыру пунктлары янындагы территорияләрдә җәмәгать тәртибен саклауда һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдә кирәкле ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

5. Мамадыш районы буенча «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССО (Д.Ф. Хаҗиев) төп гомуми белем бирү программалары, шул исәптән республика имтиханы буенча дәүләт йомгак аттестациясен уздыру пунктларында медицина персоналының дежурлыгын оештыруда ярдәм итәргә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче

И.Э. Фәттахов